# Ислам нуры

اسلام نوری

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№5 (729) | 11 март 2021 ел | (1442, Рәҗәб) | Дини-иҗтимагый газета | 1995 елдан чыга


*2021 ел - Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы*

## ҖИҢҮЧЕЛӘР БИЛГЕЛЕ



Рәҗәб аеның 13 нче көнендә, Галиев мәчетендә Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте журналистлар өчен махсус игълан иткән «Динем – ислам, милләтем – татар” дип исемләнгән иҗади эшләр бәйгесенә нәтиҗәләр ясау тантанасы үтте. Бәйгенең җиңүчеләре белән Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үзе очрашты. Күркәм гадәт буенча, ул журналистларга үзенең нәсихәт сүзләрен җиткереп, махсус бер кыска вәгазь сөйләде һәм журналистика һөнәре ияләренең Аллаһы Тәгалә каршында җаваплылыгын ассызыклап узды.

– Безнең сөйләгән сүзләребез хәерле булырга тиеш, – дип мөрәҗәгать итте мөфти. – Бервакыт Гайсә галәйһиссәлам юлдан барганда дуңгыз күрә һәм аңа тыныч кына: “Хәере белән кит!” – дип әйтә, кычкырмый. Аның сәхабәләре (гарәпчә әйткәндә хаварииннар) Гайсә галәйһиссәламнең шундый мөгамәләдә булуына гаҗәпләнәләр һәм: “Нигә дуңгызга шулай йомшак итеп эндәшәсең?” – диләр. Ә ул: “Телемне юньсезлеккә күнектермәс өчен шулай эндәштем”, – ди. Икенче көнне шәкертләр эт үләксәсенә юлыгып, аңа җирәнеп карыйлар, ә Гайсә галәйһиссәлам: “Карагыз, аның тешләре нинди матур”, – дип әйтә. Ул эт үләксәсендә дә матур якларны күрә белде. Шул рәвешле, кешеләр турында сөйләшкәндә дә аларның тискәре сыйфатларына игътибар итәргә түгел, ә уңай якларын күрә белергә кирәк. Шул вакытта гына хәерле фикер (Хусну Занн) барлыкка килер һәм телебез дә юньсез сүзләр сөйләүдән сакланыр. Әлбәттә, язган сүзләребез дөрес һәм хакыйкать булырга тиеш, ләкин һәрбер хакыйкатьне сөйләү дә дөрес түгел. Аллаһы Тәгалә барыбыздан да разый булсын!

Эчтәлекле әңгәмәдән соң, Камил хәзрәт Сәмигуллин конкурсның җиңүчеләре һәм призерларына дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр – акчалата премияләр тапшырды. «Динем – ислам, милләтем – татар” журналистлар бәйгесе җиңүчеләре:

«Иң яхшы телевизион материал» номинациясендә: I урын – Фазлыева Ләйсирә Наил кызы; II урын – Мөршидә Хәнәфи кызы Җиһан; III урын – «Татмедиа» АҖ филиалының «Заинск-информ» оешмасы коллективы.

«Иң яхшы радиорепортаж» номинациясендә: I урын – Шәрифуллина Гөлинә Мирсәет кызы; II урын – Вафина Гүзәлия Мидхәт кызы; III урын – Гыймадов Фаил Фаиз улы; Шәрәфиева Люция Рафаэль кызы.

«Басма чарада иң яхшы язма» номинациясендә: I урын – Гарифуллина Дилбәр Газил кызы; II урын – Кыямова Мөршидә Галләм кызы; Сафиуллина Рузия Фәһим кызы; III урын – Мозаффарова Эльвира Фирдүс кызы.

«Иң яхшы интернет-язма» номинациясендә: I урын – Мөхәммәтрәхимов Альфред Фәрит улы; II урын – Рәхмәтуллин Тимур Альберт улы; III урын – Шакирова Фәгыйлә Рәшит кызы; Мингалиев Минневәрис Харис улы.

Очрашуда тагын бер күркәм традиция башлап җибәрелде - озак еллар дәвамында Ислам дине кыйммәтләрен киң катлам халык арасында тарату белән шөгыльләнүче берничә журналистка Диния Нәзарәтенең “Бердәмлек” медале тапшырылды. Әлеге мәртәбәле бүләк белән үзләренең һөнәри эшчәнлеге аша милләтләр һәм диннәр арасындагы татулыкны ныгыту, исламның асыл кыйммәтләрен үстерү һәм нәзарәт белән уңышлы хезмәттәшлек өчен Фазлыева Ләйсирә Наил кызы, Гыймадов Фаил Фәиз улы һәм Җиһан Мөршидә Хәнәфи кызы бүләкләнделәр.

*(ТР МДН хәбәрләреннән)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

4 апрельдә Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында Чаллы шәһәрендә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте кубогына мөселманнарның татар милли көрәше һәм кул көрәше буенча берләштерелгән XII Рәсәйкүләм турниры узачак. Ярышта Татарстан һәм янәшә регионнардан 100 гә якын спортчы катнашыр дип көтелә. Турнирны ачу тантанасы ТР мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашында узачак. Турнир иртәнге 10:00, ә катнашучыларны теркәү 8:00 сәгатьтә башлана. Ярышлар шәһәребезнең “Витязь” спорт комплексында узачак. ТР мөселманнары Диния нәзарәте кубогына ел саен үткәрелә торган бу турнир актив һәм сәламәт яшәү рәвеше алып баручы мөселман спортчыларын берләштерүче ярыш. Һәр авырлык категориясендә җиңүчеләр дипломнар һәм кыйммәтле призлар белән бүләкләнәләр, җиңүче командага ТР МДН кубогы тапшырыла. Ә иң кыйммәтле бүләккә – Гомрә хаҗына юлламага беренче урынны яулаучылар арасында җирәбәдә отучы лаек була. Көрәшкә 18 яше тулган, физик яктан әзер һәм намаз уку кагыйдәләре буенча тест узган мөселманнар кертелә. Көрәш – 65, 75, 85, 95, 105 һәм 105 килограммнан артык категорияләрендә, кул көрәше – 70 килограммга кадәр, 85 һәм 85 килограммнан артык категорияләрендә узачак.

***



23 февраль көнне Кукмара мәдрәсәсенең кечке бүлегендә белем алучы ир-егетләр төркемнәре арасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы уңаеннан оештырылган кызыклы чара узды. Чараның беренче өлеше шәкертләрнең туган телне ни дәрәҗәдә белгәннәрен ачыклауны максат итеп куйды. Икенче өлешендә исә шәкертләргә төркем белән алдан әзерләгән “өй эшен” күрсәтергә кирәк булды. Укучыларның чыгышларын мөгаллимнәрдән торган абруйлы жюри бәяләде. Гомум нәтиҗә буенча 1 нче урынга 2 курс шәкертләре лаек булды.

# ИСЛАМ ҺӘМ ӘХЛАК ТӘРБИЯСЕ

**Әхлак тәрбиясе бөтен төр җәмгыятьтә дә, барлык милләт-кавемнәр өчен дә һәрвакыт актуаль булган һәм бүген дә актуальлеген югалтмый (югалмый гына түгел, безнеңчә, хәзерге көндә кирәге – әхлак тәрбиясе).**

Без социализм балалары, безнең буын коммунистик әхлак рухында тәрбияләнде. Тик ул тиешле ныклык һәм шәфкатьлелек тәрбияли алмады. Нәтиҗәдә, җәмгыятьтәге кискен үзгәрешләр чорында бик күпләр кыйбласын югалтты, эчкечелек артты, үз-үзенә кул салучылар күбәйде. Мәктәпләрдә дә яңа шартларда нинди тәрбия бирү мәсьәләсендә аптырап калдылар, гомумән, бу өлкәдә бер бушлык барлыкка килде. Бу бушлыкны исә әхлаксызлык күренешләре шәпләп тутырды. Урлашу, алдашу, үтерү, көчләү гадәти хәлгә, хәләл хезмәт түкми генә төрле юллар белән байлык җыю төп кәсепкә әйләнде. Наркомания, СПИД, җинаятьчелек, эшсезлек, эчкечелек киң таралды. Гасырлар буена буыннан-буынга күчеп килгән намуслылык, шәфкатьлелек, бер-береңне хөрмәт итү, ярдәмләшү, эчкерсезлек, ата-анага, олыларга хөрмәт онытыла башлады. Бу шартларда яңа таяну ноктасы, яңа төр тәрбия кирәк иде. Безнеңчә, илдә, милләтебездәге аяныч хәлдә кешелек сыйфатларын саклап калуда төп таяну ноктасы – ул исламга нигезләнгән әхлак тәрбиясе. Әхлак тәрбиясенең кайсы гына ягын алсак та, Аллаһы Тәгаләбез тарафыннан безгә төшерелгән “Коръән” китабыннан үзебезгә кирәк җавап таба алабыз. Бала гаиләдә үсә, аның холкы шунда әти-әнисе, туганнары янында формалаша. Хәзерге гаиләләргә күз салсаң, әллә нинди ямьсез күренешләргә тап буласың. Мәсәлән, кемдер әтисен, кемдер әнисен рәнҗеткән, кемдер туганнары белән бөтенләй аралашмый, хәтта әти- әнисе белән ачуланышып, аларның хәлен дә белмәүчеләр бар. “Коръән-Кәрим»дә исә ата-анага нинди мөнәсәбәт булырга тиешлеге күп тапкырлар искәртелә:

“Аллаһ хөкем итте һәм әмер бирде, фәкать Аллаһуга гына гыйбадәт кылырга һәм ата-анага изгелек итәргә. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсәләр, син аларга “Уф” та димә, вә каһәрләмә, кәефләрен җибәрмә, бәлки аларга һәрвакыт йомшак һәм мөлаем сүзләр сөйлә! Вә аларга шәфкать итеп, рәхим канатларын җәйгел! Вә әйт: “Ий, Раббым, алар мине кечкенә чагымда мәрхәмәт белән үстергәннәре кебек, Син дә аларга дөньяда һәм ахирәттә шәфкать кыл!” [“Бәни Исраил”: 23-24] , “Без кешегә ата-анасына изгелек кылырга боердык. Анасы аны карынында йөрткәндә, зәгыйфьлек өстенә зәгыйфьлек белән күтәрде. Ике ел балага сөт имезде. Миңа һәм ата-анаңа шөкер ит” [“Локман”: 14] , “Без кеше затына ата вә анага изгелек итәргә әмер бирдек...” [“Гәнкәбүт”: 8]. Ата-ананы хөрмәтләү турында хәдисләр дә күп. Аллаһы Тәгаләне таныган, дини гыйлеме булган кеше беркайчан да әти-әнисен рәнҗетмәс.

Шулай ук туганлык-кардәшлек турында да “Коръән”дә һәм хәдисләрдә күп әйтелгән. Мәсәлән, “...Аллаһуны зурлагыз вә мөселман булган якын кардәшләрегездән киселүдән сакланыгыз!..” [“Ниса”:1 ].

Әхлаклы кеше изге гамәлләр эшләргә, башкаларга ярдәм итәргә тырыша. Изге гамәлләр кылу турында Аллаһы Тәгалә түбәндәгеләрне әйткән: “...иман китереп, Ислам динен кабул иткән, һәрвакыт изге гамәлләр кылган һәм бер-берсен хаклыкка, дөреслеккә, гаделлеккә эндәшкән һәм тормыш вә дин мәшәкатьләренә, килгән төрле авырлыкларга, бәла-казаларга сабыр итәргә, чыдамлы булырга бер-берсенә эндәшкән кешеләр генә хәсрәттә-газабта булмаслар” [“Гасыр”: 3]. “Изгелектә һәм тәкъвалыкта бер-берегезгә ярдәм итегез...” [“Маидә”: 2], “...Раббыгызга гыйбадәт итегез вә мөселманнар арасында яхшылыкны кылыгыз...” [“Хаҗ”:77] һ. б. Кайбер кешеләр юк-бар нәрсә өчен дә сүзгә килеп, озак ачуланышып йөриләр, башкаларга һәм үз сәламәтлекләренә зыян салалар. Ислам дине мондый гамәлләргә каршы, ул татулыкка, килешүгә өнди: “Мал хакында низаглашудан, Аллаһудан куркыгыз һәм арагызны төзәтегез...” [“Әнфәл ”: 1], “Килешү, гафу итешү аерылышудан хәерле” [“Ниса”: 128]. Арада ниндидер ачу булса, башка кешеләр бу икәүне килештерү юлын эзләргә тиеш: “Мөэминнәр – дин буенча, әлбәттә, бер-берсенә кардәшләрдер. Кардәшләрегезнең арасын килештерегез, төзәтегез...” [“Хуҗурат”: 10]. Башкаларны, аеруча ятимнәрне рәнҗетү “Коръән”дә иң зур гөнаһлардан санала. “Бернинди начарлыкны эшләмәгән мөэмин ирләрне вә мөэминә хатыннары: “Начарлыкны эшләдең,” – дип хаксыз рәнҗетүчеләр, тәхкыйк,үзләренә бөһтанчы булуны һәм зур гөнаһны йөкләделәр” [“Әхзаб”: 58], “...ятимгә золым итмә, какма, сукма, бәлки хөрмәтлә. Һәм синнән сораучыга каты мөгаләмә кылма, ни сораса да җавап бир һәм теләген үтә” [“Зуха”: 9-10]. Тәкәбберләнеп йөрүче кешеләргә дә Аллаһы Тәгаләнең киңәшләре бар: “Кешеләр белән сөйләшкәндә, тәкәбберләнеп, яның белән сөйләшмә вә җир өстендә зураеп, мактанып вә шатланып йөрмә, тәхкыйк, Аллаһ үзенә исе китеп, мактанып йөрүчеләрне сөймидер” [“Локман”: 18]. Яхшылык кылу, кешеләрне гафу итә белү дә Аллаһы Тәгалә каршында сөекле гамәлләр: “Әлбәттә, кыямәт көне киләчәк, син кәферләрдән дөньяда үч алырга тырышма, аларга яхшылык күрсәт!” [“Хиҗр”: 85], “Ул тәкъва мөэминнәр шатлык вакытында да, кайгы вакытында да (һәм бай чакларында да, ярлы чакларында) Аллаһ күрсәткән урыннарга садака бирәләр, ачулары килгәндә ачуны йоталар, гаепле кешеләр гафу сораганда, гафу итәләр. Яхшылык кылучы әнә шундый мөэминнәрне Аллаһ сөя” [“Гимран”: 134]. Әхлак нормаларыннан булган гаделлек, намуслылык хакында да Раббыбыз безгә кирәкле кануннарны билгеләгән: “Аллаһы Тәгалә һәр эштә гадел булырга һәм дин вә мөселманнар файдасына яхшы эшләр кылырга, вә якын кардәшләрең хакын үтәргә боерадыр, вә Аллаһ сезне тыядыр фәхеш хәрам эшләрдән...” [“Нәхел”: 90], “... гаделлек белән вә тугрылык кылыгыз, тәхкыйк, Аллаһ тугрылык кылучыларны сөядер” [Хүҗүрат: 9]. Сер саклау, сүзеңдә тору, вәгъдәңне үтәү дә әхлак төшенчәсенә керә. Алар турында да “Коръән” дә сүрәләр бар: “Ий, мөэминнәр! Аллаһуга итагать итәргә биргән гәһедегезне, кешеләргә биргән вәгъдәләрегезне үтәгез!..” [“Маидә”: 1], “Ий, мөэминнәр, эшләмәгән вә эшләмәячәк эшләрне ник эшләгән булып сөйлисез? Эшләмәгән эшләрегезне эшләгән булып сөйләүләрегез – Аллаһ хозурында зур гөнаһ, бик яман эштер!” [“Саф”: 2-3].

Гап-гади генә булып күренгән сәламләшү, башкалар өенә керү турында да Аллаһ Тәгаләнең өйрәтмәләре бар: “Әгәр сезгә бер бүләктән бүләк бирелсә (сәлам бирелсә), бүләк бирүчегә артыграк бүләк бирегез яки үзегез алган бүләк хәтле бирегез...” [“Ниса”:86], “Йи, мөэминнәр, үзегезнең өйләрегездән башка өйләргә рөхсәт алмыйча һәм сәлам бирмичә кермәгез, рөхсәт сорагыз һәм өйдә булган кешеләргә сәлам бирегез... [“Нур”: 27]. Хәзерге заманда байлык артыннан куучы, мал туплау өчен теләсә нинди гөнаһлы юлларга басучылар күбәйде. Раббыбыз исә хәләл юл белән генә мал табарга, булганына шөкер итәргә куша: “...Миңа шөкер итегез, Миңа көферлек кылмагыз!” [“Бәкарә”: 152], “Әгәр нигъмәтләремә шөкер итсәгез, нигъмәтемне сезгә арттырырмын, әгәр көферлек кылсагыз, Минем газабым бик каты ” [“Ибраһим”: 7]. Һәрбер балигълыкка ирешкән һәм акылга ия кеше файдасыз сүзләрне әйтүдән телен тыярга тиеш. Без, үзебез дә аңламыйча, гадәткә кергән юк-бар сүз, башкалар турында кыек-мыек фикерләр әйтеп, зур гөнаһ җыябыз. Изге китабыбыз безне мондый эшләрдән дә кисәтә: “... кешеләрнең гаепләрен тикшермәгез, кеше гаебен эзләмәгез вә бәгъзегез бәгъзегезне гайбәт кылмасын! Әллә сезнең берәрегез үлгән кардәшенең итен ашауны сөярме? Сез, әлбәттә, аны мәкъруһ күрдегез, гайбәт сөйләүне дә шулай мәкъруһ күрегез!..” [“Хүҗүрат”: 12], “Вә дәлилең, белемең булмаган нәрсәгә иярмә, ягъни дәлилсез гамәл дә кылма, хөкем дә итмә, фәтва дә бирмә! Аллаһ биргән колак, күз, күңел – боларның һәрберсеннән кыямәт көнне сорау булыр, аларны сәваплы урыннарга гына кулланыгыз!” [“ Бәни Исраил”: 36]. Гайбәтне сөйләү генә түгел, аны тыңлау да гөнаһ. Чын мөселманнар “... буш сүзләрдән, файдасыз эшләрдән баш тарталар” [“ Мөэминнәр”: 3].

Икейөзле, ялганчы кешеләр әхлаксызлар. Раббыбыз бу турыда: “Янә үзләренә хыянәт иткән кешеләрне һәм ялганчыларны яклап тартышма, аларның эшен дөрескә санама!” - дип әйткән [“Ниса”: 107].

Кайбер кешеләр, кеше күрми дип, ярамаган гамәлләр дә кылырга мөмкиннәр, ә Аллаһы Тәгалә барысын да күреп тора, ишетеп тора, хәтта безнең калебебездә ниләр барын да белә: “Тәхкыйк, синең Раббың – фәсәд кылучы залимнәрне күзәтүче һәм җәза бирүче” [“Фәҗер”: 14], “Сүз сөйләнмәс, мәгәр сөйләнгән һәрбер сүзне көтеп утыручы фәрештә язар” [“Каф”: 18], “... нәҗестән сакланган кеби һәм ялган, бөһтан һәм пычрак сүзләрдән сакланыгыз” [“Хаҗ”: 30].

Гөнаһ кылучыларны, хаксыз яманлауны Раббыбыз тыя:” Аллаһуга ялганны ифтира кылган кешедән дә залимрәк кеше булармы? Ул залимнәр кыямәт көндә хөкемгә Раббыларына китерелерләр... Аллаһуның ләгънәте залимнәргәдер” [“Худ”: 18].

Белемсезлектән бик күп гөнаһлар, хаталар ясалган. Бу очракта да Аллаһы Тәгалә рәхимле – ярлыкау сорарга куша, Г. Тукай да бит үзенең атаклы “Туган тел” шигырен ярлыкау сорап тәмамлый:

И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:

Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

**Рәзинә МӨХИЯРОВА,**
*Чаллының «Ак мәчет» мәдрәсәсе мөгаллимәсе*

# КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕН УКУ ӨЧЕН НИЯТ КЫЛУ ТӘРТИБЕ

Коръән Кәримнән берничә аятьне, сүрәләрне берәү яттан укыса, яки карап укыса, шуны "Коръән уку" диләр. Коръән укучы иң беренче ният кылыр, ниятне күңелдән дә, телдән дә әйтергә ярый.

Ният: "Нәүәйтү ән акраәл курәнә вә әтәшшәррафә бишәрафәтил курәни лирдааир-рахмәни вә тәрдишшәйтани. Аллаһүммә йәссирһүли вә тәкаббәлһү минни". (Мәгънәсе: "Ният кылдым Коръән укымакка, аны укып хөрмәтләнмәккә. Ниятем Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешү һәм шайтаннан ерак булмак өчен. Әй Раббым, бу эшне миңа Син җиңел кыл һәм Коръән укуымны кабул ит").

Коръән укучы, мөмкинлеге булса, кыйблага карап утырыр, "Әгүзү билләһи минәш-шәйтанир-раҗиим", дияр. "Бисмилләһир-рахмәнир-рахим" – дип, укырга теләгән аятьләрен укыр.

Аллаһ Раббыбыз кылган гыйбадәтләребездән разый булып, хата-кимчелекләрне гафу итеп, укыган Коръәннәребезне кабул кылса иде. Үзебезгә дә, балаларыбызга да, якыннарыбызга да, җитәкчеләребезгә дә Коръән белән гамәл кылып, сәҗдә әһеле булып, рәхәт яшәүләребезне насыйп кылса иде. Шушы бер мизгел генә булган дөньядан мәңгелеккә күчкәндә иманыбызны юлдаш итеп, Аллаһның җәннәтләрендә дә очрашуны насыйп итсә иде.

*(«Ислам нуры» аккаунтыннан)*

***СОРАУ-ҖАВАП***

**Сорау.** "Әгузү билләһи мин әш-шәйтанир-раҗим" сүзләрен (истигаза гыйбарәсен) Коръән укый башлаганда гына кулланасы, ә башка эшне башлаганда кулланмасаң да була, дип ишеткәнем бар. Дөрес фикерне ишетәсе иде.

**Җавап.** Әйе, мәҗлесләр әдәбе буенча "әгузү билләһи мин әш-шәйтанир-раҗим" сүзләрен кулланмасаң да ярый. Бу сүзләр Коръән укуны башлаган вакытта кулланыла. Бу турыда "Фәтава әл-Хиндия" китабында китерелә: "Әгәр кеше берәр эш башларга җыенса, аңа истигаза әйтү кирәкми, ә Коръән укырга ниятләсә, истигаза әйтү тиешле була". Бу турыда "Фәтава әс-Сираҗия" хезмәтендә дә язылган.

Шулай итеп, эш башлаганда истигазадан түгел, бисмилләһтән башлау хәерлерәк. Ә Аллаһ яхшырак белүче!

*(ТР МДН фәтваларыннан)*

**ӘДӘБИ СҮЗ**

## *ҮЗ ТЕЛЕМДӘ*

*Үз телемдә дога укыйм,*
*Үз телемдә уйланам.*
*Гашыйкмын туган телемә,*
*Аһәңле ул, сокланам!*
*Үз телемдә онызгыма*
*Бишек җырларын көйлим,*
*Үз илемдә үз телемдә*
*Горурланып сүз сөйлим.*
*Тәннәр - төсле, телләр - төрле,*
*Аллаһ шулай яраткан.*
*Бер кояш, бер ай астында*
*Тату яшәргә кушкан.*
*Телен-динен кадерләгән*
*Аллаһның сөйгәнедер.*
*Гөлләр кебек телләребез*
*Җиребез күркәмедер.*
*Үз телемдә дога укыйм,*
*Үз телемдә уйланам.*
*Үз телемә рәхмәтлемен,*
*Аһәңле ул, сокланам!*

***Фәнисә ФӘХРЕТДИНОВА,***
*Башкортостанның Кушнаренко районы Әхмәт авылы*

***ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ***

# "АЛЛАҺКА ТӘВӘККӘЛЛӘП ЯШӘРГӘ КИРӘК"



Теләсә кайсы җәмгыятьтә язылган һәм язылмаган кануннар яши. Ул кануннарны аңлау һәм кабул итү, алар буенча тормыш итәргә омтылу өчен адәм баласыннан нәрсә таләп ителә? - Шул хакта Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе **Әлфәс хәзрәт ГАЙФУЛЛИН** белән сөйләшәбез.

**- Соңгы арада айныткычларны кире кайтару турында кызып-кызып сөйләшә башладылар. Әлфәс хәзрәт, сезнеңчә, кешеләрне алар белән генә "тәрбияләп" булыр микән соң?**

- Айныткычлар элек бар иде. Эчүчеләр дә бар иде, Аллаһтан курыккан кешеләр дә бар иде. Кеше кешедән ояла белә иде, эшенә хәбәр итүдән читенсенә иде, эше кадерле иде; шуңа күрә аның ише җиргә эләкмәскә тырыша иде. Ул вакытта айныткычларның бераз булса да тәэсире бар иде.

Бүген аларны кайтаруны эчкечелек белән көрәшүнең бер өлеше дип карау кирәктер. Шулай да иң башта кешенең калебендә иман һәм гыйбадәт юлы булырга тиеш, ул чагында хәрәм әйбергә якын да килмәс иде, айныткычларның да кирәге булмас иде. Аракыны тикмәгә генә "явызлыкларның анасы" димиләр бит инде. Бер риваятьне беләсездер. Мәчеткә юл тоткан берәүнең каршысына явыз хатын очрый, юмалап үз өенә дәшеп кертә. Янында сабый бала да була, хәмер салынган савыт та тора. "Яки хәмерне эчәсең, я баланы үтерәсең, я минем белән якынлык кыласың. Әгәр шуларның берсен үтәмәсәң, кычкырырмын, минем өемә керде, дип әйтермен", - ди хатын. Теге кеше уйланып кала: "Кеше үтерү - бик зур гөнаһ, моңа бармыйм; зина кылу - пычрак, фәхеш эш, аңа да бармыйм. Хәмер эчсәм, үземә генә зыян була", - ди. Хәмер эчкәч, зина да кыла, баланы да үтерә...

**- Күптән түгел Казанда булган җинаять җанны тетрәндерде. Яшь егет үзенең йөргән кызын да, аның эти-әнисен дә үтерде. Социаль челтәрләрдә күпләр, "андый вәхшигә үлем җәзасы булырга тиеш", дип фикер алыша. Сез нәрсә дияр идегез?**

- Авыр сорау. Җавап бирергә авыр. Коръәндә хөкем бар: күзгә - күз, кулга - кул, диелгән. Әгәр берәрсенең күзен чыгарды икән - шуны түләтү, нинди җәрәхәт китерсә - шуның белән җавап бирү аять белән әйтелә. Әмма бу әле "кеше берәүне үтерде икән, барып аны үтер" дигән сүз түгел. Шәригать кануны буенча, хөкемне барыбер казый кеше чыгарырга тиеш. Без ислам дәүләтендә яшәмибез, дөньяви законнар, дөньяви хөкемнәр бар. Һәр эш тикшерелә, җәзасы бирелә. Һәр кечкенә генә гөнаһ та Аллаһы Тәгалә каршында языла. Шундый аять бар: хисап көнендә зәррә кадәр - ягъни орлык кадәр генә кылынган хәерле бер эш тә күренер, орлык кадәр, кечкенә генә, гөнаһ кылдым дип уйламаган гамәл дә язылган булыр. Әгәр кеше шундый зур җинаятьләр кыла икән, аның җәзасы Аллаһ каршында булачак.

**- Телевизорны ачсаң да, газеталарга күз салсаң да, сәясәтчеләр халыкны әледән-әле "кара көнгә, кризиска" әзерләнергә чакыра. Шул чакыруга тотынып, кешеләр елы-елы белән тоз, дөге, карабодай ташып интекте. "Кризис"ны янә кибет киштәләрен штурмлап җиңәргә маташырлар микән...**

- Бу очракта бер генә җөмлә белән әйтер идем. Дөнья - бер көнлек, ахирәт - мәңгелек... Ахирәткә әзерләнергә кирәк. Без бу дөньяга ахирәткә әзерләнү өчен, мәңгелеккә әзерләнү өчен килдек. Аллаһы Тәгалә безне шуның өчен бар иткән, шуңа да җир йөзендә безне сыный. Без дөньяда яшәгәндә, дөньялыкны да алып барабыз, тик төп максатыбыз - әйткәнемчә, мәңгелеккә әзерләнү. Бүген ашарга бер көнлек ризыгың бар икән - аның өчен Аллаһка шөкер итәргә кирәк. Безнең халыкта барыбер бар инде: тегенди хәл булыр, мондый хәл булыр дип запас әзерләү. Ул запасың әллә кирәк була, әллә юк бит әле. Бозылырга да мөмкин. Аллаһка тәвәккәлләп яшәргә кирәк, чөнки барысы да Аллаһтан. Без күрәзәчелек итмибез, иманлы кеше аларга ышанмый да. Мөселман кешесе Аллаһка тәвәккәлләп яшәргә тиеш, шулвакыт аңа җиңелрәк булачак.

**Әңгәмәдәш - Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА**

# Апрель аена намаз вакытлары

| Милади апрель | Көн исеме | Шагбан, рамазан | Иртәнге намаз: Таң беленә | | | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла | | | Кояш чыга | | | Зәвал | | | Өйлә | | | Икенде | | | Ахшам | | | Ясту | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан |
| 1 | Пж | 19 | 04:48 | 02:46 | 02:59 | 05:20 | 03:31 | 03:44 | 06:48 | 05:01 | 05:14 | 13:20 | 11:34 | 11:47 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:45 | 15:59 | 16:12 | 19:53 | 18:08 | 18:21 | 21:23 | 19:57 | 20:10 |
| 2 | Жм | 20 | 04:46 | 02:43 | 02:56 | 05:18 | 03:28 | 03:41 | 06:46 | 04:58 | 05:11 | 13:20 | 11:33 | 11:47 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:46 | 16:00 | 16:13 | 19:55 | 18:10 | 18:23 | 21:25 | 19:59 | 20:13 |
| 3 | Шм | 21 | 04:43 | 02:39 | 02:52 | 05:15 | 03:26 | 03:39 | 06:43 | 04:56 | 05:09 | 13:19 | 11:33 | 11:46 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:48 | 16:02 | 16:15 | 19:57 | 18:12 | 18:25 | 21:27 | 20:02 | 20:15 |
| 4 | Як | 22 | 04:41 | 02:36 | 02:49 | 05:13 | 03:23 | 03:36 | 06:41 | 04:53 | 05:06 | 13:19 | 11:33 | 11:46 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:49 | 16:03 | 16:16 | 19:59 | 18:14 | 18:27 | 21:29 | 20:05 | 20:18 |
| 5 | Дш | 23 | 04:38 | 02:32 | 02:45 | 05:10 | 03:20 | 03:33 | 06:38 | 04:50 | 05:03 | 13:19 | 11:33 | 11:46 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:50 | 16:05 | 16:18 | 20:01 | 18:16 | 18:29 | 21:31 | 20:07 | 20:21 |
| 6 | Сш | 24 | 04:36 | 02:29 | 02:42 | 05:08 | 03:18 | 03:31 | 06:36 | 04:48 | 05:01 | 13:19 | 11:32 | 11:45 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:52 | 16:06 | 16:19 | 20:03 | 18:18 | 18:31 | 21:33 | 20:10 | 20:23 |
| 7 | Чш | 25 | 04:33 | 02:25 | 02:38 | 05:05 | 03:15 | 03:28 | 06:33 | 04:45 | 04:58 | 13:18 | 11:32 | 11:45 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:53 | 16:07 | 16:21 | 20:04 | 18:20 | 18:33 | 21:34 | 20:13 | 20:26 |
| 8 | Пж | 26 | 04:31 | 02:21 | 02:34 | 05:03 | 03:13 | 03:26 | 06:31 | 04:43 | 04:56 | 13:18 | 11:32 | 11:45 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:55 | 16:09 | 16:22 | 20:06 | 18:22 | 18:35 | 21:36 | 20:16 | 20:29 |
| 9 | Жм | 27 | 04:28 | 02:18 | 02:30 | 05:00 | 03:10 | 03:23 | 06:28 | 04:40 | 04:53 | 13:18 | 11:31 | 11:45 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:56 | 16:10 | 16:23 | 20:08 | 18:24 | 18:37 | 21:38 | 20:19 | 20:32 |
| 10 | Шм | 28 | 04:26 | 02:14 | 02:27 | 04:58 | 03:08 | 03:21 | 06:26 | 04:38 | 04:51 | 13:17 | 11:31 | 11:44 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:57 | 16:12 | 16:25 | 20:10 | 18:26 | 18:39 | 21:40 | 20:21 | 20:35 |
| 11 | Як | 29 | 04:23 | 02:10 | 02:23 | 04:55 | 03:05 | 03:18 | 06:23 | 04:35 | 04:48 | 13:17 | 11:31 | 11:44 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:59 | 16:13 | 16:26 | 20:12 | 18:28 | 18:41 | 21:42 | 20:24 | 20:38 |
| 12 | Дш | 30 | 04:21 | 02:06 | 02:19 | 04:53 | 03:02 | 03:15 | 06:21 | 04:32 | 04:45 | 13:17 | 11:31 | 11:44 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:00 | 16:14 | 16:28 | 20:14 | 18:30 | 18:43 | 21:44 | 20:27 | 20:41 |
| 13 | Сш | 1 | 04:18 | 02:02 | 02:15 | 04:50 | 03:00 | 03:13 | 06:18 | 04:30 | 04:43 | 13:17 | 11:30 | 11:44 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:01 | 16:16 | 16:29 | 20:16 | 18:32 | 18:45 | 21:46 | 20:30 | 20:44 |
| 14 | Чш | 2 | 04:16 | 01:58 | 02:11 | 04:48 | 02:57 | 03:10 | 06:16 | 04:27 | 04:40 | 13:16 | 11:30 | 11:43 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:03 | 16:17 | 16:30 | 20:18 | 18:34 | 18:47 | 21:48 | 20:33 | 20:47 |
| 15 | Пж | 3 | 04:14 | 01:54 | 02:07 | 04:46 | 02:55 | 03:08 | 06:14 | 04:25 | 04:38 | 13:16 | 11:30 | 11:43 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:04 | 16:19 | 16:32 | 20:20 | 18:36 | 18:49 | 21:50 | 20:36 | 20:50 |
| 16 | Жм | 4 | 04:11 | 01:50 | 02:02 | 04:43 | 02:52 | 03:05 | 06:11 | 04:22 | 04:35 | 13:16 | 11:30 | 11:43 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:05 | 16:20 | 16:33 | 20:22 | 18:38 | 18:52 | 21:52 | 20:39 | 20:53 |
| 17 | Шм | 5 | 04:09 | 01:45 | 01:58 | 04:41 | 02:50 | 03:03 | 06:09 | 04:20 | 04:33 | 13:16 | 11:29 | 11:43 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:07 | 16:21 | 16:34 | 20:24 | 18:40 | 18:54 | 21:54 | 20:42 | 20:56 |
| 18 | Як | 6 | 04:06 | 01:41 | 01:54 | 04:38 | 02:47 | 03:00 | 06:06 | 04:17 | 04:30 | 13:15 | 11:29 | 11:42 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:08 | 16:23 | 16:36 | 20:26 | 18:42 | 18:56 | 21:56 | 20:46 | 20:59 |
| 19 | Дш | 7 | 04:04 | 01:37 | 01:49 | 04:36 | 02:45 | 02:58 | 06:04 | 04:15 | 04:28 | 13:15 | 11:29 | 11:42 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:09 | 16:24 | 16:37 | 20:28 | 18:44 | 18:58 | 21:58 | 20:49 | 21:02 |
| 20 | Сш | 8 | 04:02 | 01:32 | 01:45 | 04:34 | 02:43 | 02:56 | 06:02 | 04:13 | 04:26 | 13:15 | 11:29 | 11:42 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:10 | 16:25 | 16:38 | 20:29 | 18:46 | 19:00 | 21:59 | 20:52 | 21:06 |
| 21 | Чш | 9 | 03:59 | 01:27 | 01:40 | 04:31 | 02:40 | 02:53 | 05:59 | 04:10 | 04:23 | 13:15 | 11:29 | 11:42 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:12 | 16:27 | 16:40 | 20:31 | 18:48 | 19:02 | 22:01 | 20:56 | 21:09 |
| 22 | Пж | 10 | 03:57 | 01:23 | 01:35 | 04:29 | 02:38 | 02:51 | 05:57 | 04:08 | 04:21 | 13:15 | 11:28 | 11:42 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:13 | 16:28 | 16:41 | 20:33 | 18:50 | 19:04 | 22:03 | 20:59 | 21:12 |
| 23 | Жм | 11 | 03:55 | 01:18 | 01:30 | 04:27 | 02:35 | 02:48 | 05:55 | 04:05 | 04:18 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:14 | 16:29 | 16:42 | 20:35 | 18:52 | 19:06 | 22:05 | 21:02 | 21:16 |
| 24 | Шм | 12 | 03:52 | 01:13 | 01:25 | 04:24 | 02:33 | 02:46 | 05:52 | 04:03 | 04:16 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:15 | 16:30 | 16:44 | 20:37 | 18:54 | 19:08 | 22:07 | 21:06 | 21:19 |
| 25 | Як | 13 | 03:50 | 01:07 | 01:20 | 04:22 | 02:31 | 02:44 | 05:50 | 04:01 | 04:14 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:17 | 16:32 | 16:45 | 20:39 | 18:56 | 19:10 | 22:09 | 21:10 | 21:23 |
| 26 | Дш | 14 | 03:48 | 01:02 | 01:14 | 04:20 | 02:28 | 02:41 | 05:48 | 03:58 | 04:11 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:18 | 16:33 | 16:46 | 20:41 | 18:58 | 19:12 | 22:11 | 21:13 | 21:27 |
| 27 | Сш | 15 | 03:46 | 00:56 | 01:09 | 04:18 | 02:26 | 02:39 | 05:46 | 03:56 | 04:09 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:19 | 16:34 | 16:47 | 20:43 | 19:00 | 19:14 | 22:13 | 21:17 | 21:31 |
| 28 | Чш | 16 | 03:43 | 00:50 | 01:03 | 04:15 | 02:24 | 02:37 | 05:43 | 03:54 | 04:07 | 13:14 | 11:27 | 11:40 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:20 | 16:36 | 16:49 | 20:45 | 19:02 | 19:16 | 22:15 | 21:21 | 21:34 |
| 29 | Пж | 17 | 03:41 | 00:44 | 00:56 | 04:13 | 02:21 | 02:34 | 05:41 | 03:51 | 04:04 | 13:13 | 11:27 | 11:40 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:21 | 16:37 | 16:50 | 20:47 | 19:04 | 19:18 | 22:17 | 21:25 | 21:38 |
| 30 | Жм | 18 | 03:39 | 00:37 | 00:49 | 04:11 | 02:19 | 02:32 | 05:39 | 03:49 | 04:02 | 13:13 | 11:27 | 11:40 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:22 | 16:38 | 16:51 | 20:49 | 19:06 | 19:20 | 22:19 | 21:29 | 21:42 |

*Балалар өчен*

**Фәйрүзә МӨСЛИМОВА**

## ТАТАР ӘЛИФБАСЫ



Жиләккә чыктым аланга
Кәрзин тотып кулыма.
И сыйланам! Ә кәрзинем...
Ашыкмый шул туларга.

Кәрзинем дә тулсын өчен
Чикләү кирәк үземне.
Йа, Аллаһым, шуның өчен
Сабырлыклар бир инде!..

Запас җыйган житез тиен
Зур имән куышында.
Гөмбә дә бар, чикләвек тә...
Нигә кыштан куркырга?

Аллаһ шулай барлык затка
Ризыгын биреп тора.
Тик һәрбер зат эшләп ашый –
Үзе дә гамәл кыла.



*Саулыгым-байлыгым*

## ЙӨЗЬЯШӘР (АЛОЭ)



Алоэ согы витаминнарга һәм минералларга, аерым алганда A, B1, B2, B3, B12, C витаминнарына, фолий кислотасы, кальций, тимер, магний, натрий, калий, цинк, хром, бакырга бай. Дәвалау үзлегенә ия булган алоэ гөле халык медицинасында да киң кулланыла. Ул иммунитетны яхшырта, вируслы инфекцияләргә каршы торырга булыша. Алоэның согын косметологиядә дә файдаланалар. Алоэ согы коры бит тиресен дымландыра, тиредәге ялкынсынуны бетерә, бетчәләргә каршы көрәшә, чәч коелуны туктата. Алоэ согы белән зәйтүн маен бертигез күләмдә алып, йоклар алдыннан кулыгызга сылагыз. Бит тиресе коры булганда, бертигез күләмдә алоэ согы, солы оны, юкә балы һәм зәйтүн маен яхшылап болгатыгыз да битегезгә сылагыз. 10-15 минуттан юып төшерегез. Бит тиресе майлы булганда, лимон белән алоэ согын бертигез күләмдә алып, шуны битегезгә сылагыз. Җыерчыклардан котылу өчен ике зур алоэ гөле яфракларын блендерда изегез дә, бер стакан су салып, боз итеп катырыгыз. Һәр көн иртән шуны битегезгә ышкыгыз.

Нәшире
Иршат Гыйльметдин улы
ШӘЙХАТТАР
Баш мөхәррир
Муллагалиева А. Г.
Тел.: (8552) 70-51-09
Факс: (8552) 70-51-45

* * *

Оештыручылары:
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.

Электрон хатлар өчен:
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

Айга ике мәртәбә чыга.

Бу санның тиражы: 1210
Индексы 54149

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп, динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
423802, Яр Чаллы,
Үзәк урамы, 72

Басарга кул куелды:
график буенча
11 март 16 сәг.
фактта 11 март 16 сәг.
Бәясе ирекле